КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 март г.Казань № 221

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Аңлатма язуы» бүлегендә:

җиденче абзацта «181 махсус сакланыла торган табигать объектын» сүзләрен «184 махсус сакланыла торган табигать территориясен» сүзләренә алыштырырга;

унынчы абзацта «33» саннарын «36» саннарына алыштырырга;


ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табигать-тыюлык фондының гомуми мәйданы 398,342 мең гектар яки республиканың гомуми мәйданының 5,65 процентын тәшкил итте, бу 1997 елның күрсәткеченнән (1,03 процент) алты тапкырга артып китте.»;

«Әгерҗе муниципаль районы» бүлегендә:

Әгерҗе муниципаль районы карта-схемасын һәм аңарга искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгерҗе муниципаль районы





[28] – река Казанка
[29] – река Шошма
[30] – Рукотворный лес
[31] – Корсинская колония серой цапли
[32] – Исток реки Казанки
[33] – Янга-Салинский склон
[34] – Лес Тукай-Кырлай
[174] – Аю урманы
[35] – Сурнарский
[8р] – Водоохранная зона реки Кисьмесь
[203] – Шорский»;

[28] – Казансу елгасы
[29] – Шушма елгасы
[30] – Кул белән утыртылган урман
[31] – Соры челәннең Курса колониясе
[32] – Казансу елгасының башы
[33] – Яңасала сөзәклеге
[34] – Тукай-Кырлай урманы
[174] – Аю урманы
[35] – Сорнар
[8р] – Кесмәс елгасының су саклау зонасы
[203] – Шорский»;

түбәндәге эчтәлекле «Шорский [203]» бүлекчәсен өстәргә:

«Шорский [203]

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 февраль, 64 нче карары |
| Урнашкан урыны | Татарстан Республикасының Арча, Биектау һәм Зеленодольск районнары |
| Тикшерүдә тотучы дәүләт башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты |



Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. 10 715 гектар гомуми мәйданлы тыюлык Арча, Биектау һәм Зеленодольск районнары территорияләрендә урнашкан.

Тыюлыкны оештыру максаты – тайга экосистемаларын саклау. Гамәли максаты – суер, боҗыр, ак куянның югары тыгызлыкта булуын торгызу.

Тыюлыкның бурычлары:

бертиптагы төрләр өчен уңайлы шартлар (комплекста) тудырырга һәм суер, боҗыр, ак куянның югары тыгызлыкта булуын тәэмин итәргә;

төрләрне саклау һәм актив файдалануны бергә алып барырга;

төньяк урман боланын, тиенне, мөмкин булса тешне ирексез яшәү шартларында торгызу эшен үткәрергә.

Барлык участокларда да аеруча бертип тайга төрләре: суер, боҗыр, ак куян сакланган. Боҗырның булуы аеруча кыйммәтле булып тора, чөнки бу төр үз гомерен тайганың бик караңгы участокларында үткәрә һәм шуңа да ул участокның караңгы ылыслы тайга экосистемасына каравын күрсәтә торган индикатор булып тора. Тыюлыкта берәр-берәр бертип төньяк тайга хайваннары сакланган: кызыл кыр тычканы, төньяк Архангельск тиене; Зеленодольск хуҗалыгында кама, селәүсен, сакаллы соры ябалаклар билгеләнгән, Илләт елгасында үсемлекләрнең бертип тайга участоклары (ак чыршы участоклары белән биек кәүсәле нарат-чыршы урманнары) сакланган.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.»;

«Биектау муниципаль районы» бүлегендә:

Биектау муниципаль районы карта-схемасын һәм аңарга искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Биектау муниципаль районы




[28] – река Казанка
[61] – Голубые озера
[62] – озеро Карасиное
[63] – озеро Кара-Куль
[64] – озеро Мочальное
[80] – озеро Русско-Марийские Ковали
[65] – Эстачинский склон
[66] – Семиозерский лес
[169] – Чулпан
[203] – Шорский»;

[28] – Казансу елгасы
[61] – Зәңгәр күлләр
[62] – Кәрәкәле күле
[63] – Каракүл күле
[64] – Мунчала күле
[80] – Урыс-Мари Ковалы күле
[65] – Эстачи сөзәклеге
[66] – Семиозерка урманы
[169] – Чулпан
[203] – Шорский»;

түбәндәге эчтәлекле «Шорский [203]» бүлекчәсен өстәргә:

«Шорский [203]

(к. Арча районы)»;

«Зеленодольск муниципаль районы» бүлегендә:

Зеленодольск муниципаль районы карта-схемасын һәм аңарга искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы




[25] – Зөя елгасы
[59] – Свияжский
[76а] – Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы (Раифа участогы)
[78] – Аксусыз күле
[79] – Провальное күле
[81] – Собакино күле
[82] – соры челән колониясе
[83] – Ильинский ерымы
[84] – «Никольский» чокыр-ерым системасы
[85] – «Фәхри Яры» чокыр-ерым системасы
[86] – «Кишәнгер» чокыр-ерым системасы
[203] – Шорский»;

түбәндәге эчтәлекле «Шорский [203]» бүлекчәсен өстәргә:


«Шорский [203]

(к. Арча районы)»;

«Мамадыш муниципаль районы» бүлегендә:

Мамадыш муниципаль районы карта-схемасын һәм аңарга искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы




[122] – река Берсут
[123] – Сокольский лес
[124] – Берсутские пихтарники
[125] – Мешебашское лесничество (пихтарник Порфирьева)
[126] – Мешинский
[53р] – Геологический разрез «Омарский починок»
[54р] – Сабинский лесхоз, 372 квартал
[55р] – урочище «Липовая грива»
[56р] – Сокольский
[200] – Нерестилище стерляди
[202] – Нократ»;


[122] – Берсут елгасы
[123] – Сокольский урманы
[124] – Берсут ак чыршы урманнары
[125] – Мишәбаш урманчылыгы (Порфирьев ак чыршы урманнары)
[126] – Мишә
[53р] – «Омарский починок» геология кисеме
[54р] – Саба урман хуҗалыгы, 372 квартал

[55р] – «Юкә ялы» урыны
[56р] – Сокольский
[200] – Чөгә балыгы уылдык чәчү урыны
[202] – Нократ»;

түбәндәге эчтәлекле «Нократ [202]» бүлекчәсен өстәргә:

«Нократ [202]

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 февраль, 57 нче карары |
| Урнашкан урыны | Татарстан Республикасының Мамадыш районы, Мамадыш шәһәреннән көньяк-көнбатышта |
| Тикшерүдә тотучы дәүләт башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты |



Объектның тасвирнамәсе һәм анық әһәмияте. 1 380,72 гектар гомуми мәйданлы тыюлык Мамадыш районының көньяк-көнчыгыш өлешендәге Нократ елгасы үзәнендә урнашкан һәм тугай тибындагы су-сазлык биләмәләре участогыннан гыйбарәт.

Тыюлык территориясенең ландшафт төрлелеге үз эченә борынгы күлләрне, сазлык массивларын, кара зирек һәм тал урманнарын, тугай болыннарын ала.

Бу территория суда һәм су янында үсә торган бик күп үсемлекләрнең яшәү урыны булып тора. Биредә үсемлекләрнең Татарстан Республикасы өчен Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләре үсә: сары төнбоек, сазлык йод үләне, себер кылыч уты һ.б. Хайваннар арасыннан ак коерыклы диңгез бөркете, кабер бөркете, лачын сапсан, ысылдавык ак кош, кыштуар, соры торна һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән башка төрләр теркәлгән.

Территориядә кыргый үрдәкләрне үрчетү өчен оптималь шартлар бар. Бу төрне торгызу буенча махсус чаралар таләп ителә. Бу табигать комплексын махсус саклауның максатка ярашлы булуы үзән комплексының су режимын саклау кирәклеге белән дә аңлатыла.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.»;

«Нурлат муниципаль районы» бүлегендә:

Нурлат муниципаль районы карта-схемасын һәм аңарга искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нурлат муниципаль районы




[134] – река Большой Черемшан
[9] – река Большая Сульча
[135] – озеро Кара-Куль
[12] – Билярский государственный охотничий заказник
[188] – Чирмешэн болыннары
[60р] – Большой Черемшан
[204] – Черемшанский»;


[134] – Олы Чирмешән

[9] – Олы Сөлчә
[135] – Каракүл күле
[12] – Биләр дәүләт аучылык тыюлыгы
[188] – Чирмешән болыннары
[60р] – Олы Чирмешән
[204] – Чирмешән»;

түбәндәге эчтәлекле «Чирмешән [204]» бүлекчәсен өстәргә:

«Чирмешән [204]

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 февраль,74 нче карары |
| Урнашкан урыны | Татарстан Республикасының Нурлат районы, Салдакай авылыннан көнбатышка таба Зур Чирмешән елгасы үзәнендә урнашкан |
| Тикшерүдә тотучы дәүләт башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты |



Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. 2 344 гектар гомуми мәйданлы тыюлык Нурлат районының көньяк-көнбатыш өлешендәге Салдакай авылыннан көнбатышка таба Олы Чирмешән елгасы үзәнендә урнашкан һәм су-сазлык комплексы булып тора.

Тыюлыкта төрле типтагы сулыклар: елгалар, борынгы күлләр, сазлыклар, күлләр урнашкан. Сезон саен су белән капланган түбәнлекләр бик күп. Су янында үсә торган ешлыклар, төрләре төрле составта булган урман участоклары киң урын алып тора. Бу шартларда флора һәм фаунаның күбрәк гидрофильле вәкилләреннән торган бай табигать комплексы барлыкка килгән. Татарстан Республикасының Кызыл китабына һәм Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән умырткалыларның кайбер төрләре монда төбәккә хас аеруча тыгыз төркемнәрне формалаштыра: сазлык ябалагы, сары ябалак, гади кыштуар, гади шөпшә кошы, зур бөркетсыман кош, камыш чыпчыгы. Гамәлдәге экосистеманы саклап калудан тыш, тыюлык кыргый үрдәк санын торгызу эшләре полигоны булып хезмәт итә.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин